Мордовиядә «Ватанны саклаучылар» дәvләт фонды СВО ветеранынын торагын «Акыллы йорт» системасына жайлаштырган.

Мордовия Республикасында «Ватанны саклаучылар» махсус хәрби операциясендә катнашучыларга ярдәм итv дәvләт фонды филиа-лы авыр яраланган яклаучы очен торакны югары технологияле адаптацияләv проектын гамәлгә ашырды. Атяшево районында яшәvче Виктор Суглин СВО уздыру зонасына 2023 елнын августында vз теләге белән киткән. Авдеевка шәһәре янында ул дрон атакасы нәтижәсендә авыр яралана, ике аягын да югалта. Кvрсәткән батырлыгы һәм каһарманлыгы очен ветеран Батырлык ордены белән бvләкләнә.

Ойгә кайткач, Виктор Госфон-дынын социаль координаторы Елена Жданкинага персональ озату-сопровождениесенә кергән. Анын сvзләренә караганда, алган жәрәхәтләренә карамастан, ветеран актив тормыш рәвеше алып бара: ул дайвинг, йозv, ат һәм тау чангысы спорты белән унышлы шогыльләнә. Берничә тапкыр «Ватанны саклаучылар кубогы» ярышларында да катнашкан.

Дәvләт фонды чаралары хисабына, комплексლы ярдәм кысаларында, Виктор Суглин кул белән идарә ителә торган яна «Москвич 3» автомобиле, заманча спорт протезлары һәм адаптив кием комплекты белән тәэмин ителгән. Үз тәжрибәсен балаларга тапшыру очен алга таба vсәргә теләп, Виктор һонәри белем алу очен педагогия коллиятенә документларын тапшырган.

Социаль тернәкләндерvнен топ этабы - Викторнын торагын заманча «Акыллы йорт» системасы белән жиһазлау. Социаль координатор ярдәмендә ветераннын фатирында махсус кухня, компьютерлы эш урыны, робот-тузан суырткыч, тәрәзәләрне дистанцион ачу системасы һәм борылмалы козге булган.

- Кухня бик унайлы, - ди Виктор. Мин vзем материалларны, тосне һәм дизайны; тоташ остәл ослеге, раковинаны, индукцион плитә һәм СВЧ мичне сайладым. Аерым шатлык мостәкыйль рә-вештә идәнне себерә һәм юа торган робот-пылесос, шулай ук телефондагы махсус кушымта аша хәтта ойдән читтә дә тәрәзәләрне ачу-ябу момкинлеге тудырды. Эш урынынын моһим элементы адаптив остәл булды, анын остәл ослегенен биеклеген шунда ук тоймәләр ярдәмендә койләргә момкин.

«Ватанны саклаучылар» дәvләт фонды Россия Президенты Владимир Путин Указы буенча тозелде. Анын топ максаты - СВО ветераннарын һәм геройларнын гаилә әгъзаларын шәхсән озатып йорv. Фонднын белгечләре һәм социаль координаторлары яклаучыларга медицина һәм социаль реабилитация белән генә тvгел, ә янадан укытуда һәм эшкә урнашуда да ярдәм итәләр, юридик яктан булышалар, торакны инвалидлар ихтыяжларына яраклаштыралар һәм озак вакыт ойдә карауны тәэмин итәләр. Фондны статс-секретарь – РФ оборона министры урынбасары Анна Цивилева житәкли. Фонд

филиаллары Россиянен барлык төбәкләрендә дә эшли.

Наилә НАСЫРОВА әзерләде,
Фото: «Ватанны Саклаучылар» Дәүләт Фонды сайтыннан